28. Rakhmatullina, A., Khadieva, G. K. (2023). *Balalar soylamena fonosemantik analiz (Golina Shaikhi shigyre misalynda)* [Phonosemantic Analysis of Children's Speech (using the example of Gulina Shaikhi's poem)]. Khakovskie chteniya – 2023: materialy Mezhdunarodnoi nauchno-prakticheskoi konferentsii molodykh uchenykh, posvyashchennoi pamyati zasluzhennogo professora Kazanskogo universiteta Vakhita Khozyatovicha Khakova (Kazan', 26–27 oktyabrya 2023 g.) / pod obshch. red. G.R. Galiullinoi. Pp. 91–94. Kazan, Izdatel'stvo Kazanskogo universiteta. URL: https://kpfu.ru/portal/docs/F1473185455/Sbornik_Khakovskie.chteniya_2023.pdf (accessed: 24.07.2024). (In Tatar)

# КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНДА ӘДӘБИ ИҖАТ ТҮГӘРӘКЛӘРЕ ТАРИХЫ ҺӘМ АЛАРНЫҢ XX-XXI ГАСЫР ТАТАР ӘДӘБИЯТЫН ҮСТЕРҮДӘГЕ РОЛЕ

**Халисә Хатыйп кызы Кузьмина,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
shirmanx@yandex.ru

**Гөлфия Расил кызы Гайнуллина,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
gulfiarasilevna@mail.ru

Әдәби иҗат түгәрәкләре һәм берләшмәләре халыкның рухи мәдәнияте югарылыгын билгели торган әһәмиятле иҗтимагый күренеш булып тора. Тарих шуны күрсәтә: әдәби берләшмәләр эшчәнлеге милли әдәбият һәм мәдәният үсешенә нигез салып кына калмыйча, дәүләткә һәм аның эчке сәясәтенә дә йогынты ясарга мөмкин, шуңа күрә мондый берләшмәләрнең тарихын өйрәнү хәзерге заман әдәби процессны аңлау өчен дә актуаль. Казан университетында милли иҗат берләшмәләре һәм түгәрәкләре барлыкка килүнең үзенчәлекле тарихы бар. Биредә татар телле әдәби түгәрәкләр татар теле фундаменталь рәвештә укытыла башлагач, ягъни XX гасырда барлыкка килеп, берничә тапкыр үзгәргәннәр һәм бүгенге көнгә кадәр үз эшчәнлекләрен дәвам итәләр. Әлеге мәкаләдә Казан университетында оешкан әдәби иҗат берләшмәләренең тарихын тасвирлау, аларның эшчәнлеген шул чордагы иҗтимагый-тарихи шартлар һәм мохит белән бәйләп өйрәнү; бу өлкәдә хезмәт куйган укытучыларны, язучыларны һәм аларның фәнни-педагогик эшчәнлеген ачыклау бурычы куела.

**Төп төшенчәләр:** Казан университеты, әдәби иҗат, берләшмә, түгәрәк, язучылар, «Әллүки», «Илһам», «Дастан», «Рухият»

## Кереш

Кеше иҗтимагый зат буларак интерпретацияләнә һәм җәмгыятьтән читтә яши алмый. Нәкъ менә башка кешеләр белән аралашу, ягъни иҗтимагый мөнәсәбәтләр кешене табигатьтән аерып чыгара. Иҗтимагый мөнәсәбәтләр индивидуумнарның төрле социаль төркемнәргә берләшүен шарт итеп куя. Яшәү рәвеше, якынлык, мәнфәгатьләр, туганлык, традицияләр һ.б. билгеләр буенча берләшкән зур булмаган төркемнәрдә соңыннан җәмгыятьтә кабул ителә ала торган нормалар булдырырга мөмкин. Мондый иҗтимагый төркемнәр (бергәлекләр,

берләшмәләр) кешелекнең бөтен тарихы дәвамында барлыкка килә [1, б. 3] һәм Идел буе төбәге өчен дә ят күренеш түгел.

XVIII-XIX гасырлар чигендә Казанның мәдәни тормышы бай һәм күптөрле буларак тасвирлана. Бу вакытта Г.П. Каменев һәм С.А. Москотильников кебек яшь әдәбиятчылар Идел буеның беренче әдәби түгәрәкләренең берсен оештыралар [2]. 1804 елда университет ачылу (Идел буенда беренче һәм Россиядә өченче университет) Казан һәм төбәк тормышында әһәмиятле вакыйга була. Биредә Идел буе, Урал һәм Себер өчен укытучылар, табиблар, инженерлар, юристлар, чиновниклар әзерләнгән. Шул ук вакытта университет составында сүз сәнгате бүлеге булуы филологик белем һәм әдәби иҗат үсүенә яңа мөмкинлекләр ача.

Әдәби түгәрәк – әдәбият белән кызыксынучы кешеләр берләшмәсе, аның әгъзалары әдәби барыш *(әдәби процесс)* турында фикер алышалар, үз иҗатлары белән уртаклашалар, язучылар стилен һәм язу техникасын анализлыйлар, шулай ук язу осталыгы буенча остаханәләр үткәрә алалар. Гадәттә, мондый түгәрәкләр һәм берләшмәләр идея-фикерләр алышу, иҗатта бер-берсенә ярдәм итү өчен барлыкка килә.

Әдәби түгәрәкләр эшчәнлеге Казан университеты оешуының беренче елларыннан ук башланып китә, әмма алар рус телле студентлар өчен оештырыла. Татар телле әдәби түгәрәкләр эшчәнлеге исә бары тик XX гасырның беренче чиреге ахырында гына активлаша.

## Тикшеренү материаллары һәм методлары, фәнни яңалыгы

Әлеге мәкаләдә Казан университетында оешкан әдәби иҗат берләшмәләренең тарихын тасвирлау, бу өлкәдә хезмәт куйган укытучыларны, язучыларны һәм аларның фәнни-педагогик эшчәнлеген барлау бурычы куела.

Төрле берләшмәләрнең эшчәнлеген тикшергәндә, Казан университеты оешкан елларда ук барлыкка килгән әдәби берләшмәләрнең бербөтен картинасын төзү өчен хронологик эзлеклелек алымы кулланылды. Шул ук вакытта берләшмәләр эшчәнлегенең әһәмиятле тенденцияләрен анализлау өчен кайбер очракларда материалны тикшерүгә проблемалы якын килү алымы да искә алынды. Мәкаләдә бәян итүнең хронологик һәм проблемалы принциплары бергә кушыла. Тарихи-чагыштырмалы һәм аксиологик методлар әдәби берләшмәләр эшчәнлеген бүгенге көн һәм узган гасыр күзлегеннән бәяләргә ярдәм итте.

Әлеге темага караган кайбер эзләнүләр булса да, Казан университетында эшчәнлек алып барган татар телле әдәби түгәрәкләр һәм берләшмәләрнең барлыкка килү һәм үсеш тарихын ачыклап язылган хезмәтләр юк диярлек. Бу уңайдан Ф.Г. Галимуллинның Татар дәүләт гуманитар педагогика университетында озак еллар дәвамында эшләп килгән «Илһам» түгәрәгенең тарихын яктырткан мәкаләсен [3] һәм Х.Х. Кузьминаның Казан дәүләт университетында эшчәнлек алып барган «Әллүки» түгәрәге тарихын яктырткан мәкаләләрен күрсәтергә мөмкин [4]. Аерым язмаларда түгәрәкләргә йөрүчеләрнең шәхси истәлекләре һәм түгәрәк утырышлары турында уйланулары урын ала (Мәдинә Җәләлиева, Ленар Шәех, Сәрбиназ Шәйхеллова, Булат Ибраһимов һ.б.). Казанда XX гасыр башында эшләгән рус телле әдәби салоннар һәм берләшмәләр, «Амур», «Болгар» кунакханәләрендә узган әдәби җыеннар, «Шәрык» клубы, «Октябрь» һәм «Сулф» әдәби җәмгыятьләре турында А.Е. Демиркаяның «Казандагы әдәби җыелышлар: салон әңгәмәләреннән алып әдәби җәмгыятьләргә кадәр» дип аталган фәнни мәкаләсендә тасвирлана [5].

Шул рәвешле, тикшеренүнең фәнни яңалыгы Казан университетында оешкан татар телле әдәби иҗат түгәрәкләрен һәм берләшмәләре тарихын ачыклау һәм, гомумиләштереп, киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим итүдән гыйбарәт.

## Фикер алышу

1917 нче елгы инкыйлаблар университет тарихына зур үзгәрешләр алып килә. Югары катлам нәселеннән булган студентлар әкрен генә юкка чыга, эшче һәм крестьяннардан торган эшче факультетлар (рабфак) төзелә, күпсанлы иҗтимагый һәм сәяси түгәрәкләр оеша башлый, төгәл фәннәрне татар телендә укыту проблемасы куела. Совет властеның беренче елларында ук татар теле уку предметы буларак, югары мәктәпкә актив кертелә башлый [6, б. 19] Беренче вакытта татарлардан гына торган утыз кешелек ике төркем оеша, аннан бу төркемнәрнең саны алтыга җиткерелә. Әмма төрле фәннәрне татар телендә

укытырлык педагогик кадрлар булмау сәбәпле, бу төркемнәр таркала [7, б. 132]. 1920-1930 елларда исә Казан университетында татар теле М.Х. Корбангалиев җитәкчелегендә икенче дәүләт теле буларак укытыла башлый.

Казанда бу елларда университеттан тыш татар телле иҗади түгәрәкләрнең эшләве мәгълүм. Иҗади берлекләрнең яңа формаларын эзләү һәм татар язучыларын берләштерү омтылышлары 1920 еллар башыннан ук ясала. Мәсәлән, 1923 елда К. Нәҗми «Завод» әдәби түгәрәген, Ш. Усманов «Часовой» әдәби берләшмәсен оештыра [8]. 1924 ел башында Казанның Үзәк Коммунистлар клубы каршында зуррак берләшмә – «Октябрь» җәмгыяте оештырыла. 1924 елның апрелендә аның Гадел Кутуй һәм Гомәр Толымбайский җитәкчелегендәге әгъзаларының бер өлеше «Октябрь»дән чыгып, мөстәкыйль «Сулф» берләшмәсен оештыралар, әмма ул бераздан таркала. «Казанда татар әдәби көчләренең интенсив рәвештә тупланыуы барлыкка килде. 1923-24 елларда яшь әдәби көчләр «Октябрь» һәм «Сулф» (сул фронт) кебек «әдәби күмәкләрне» төзиләр. Боларда Кави Нәҗми, Һади Такташ, Гадел Кутуй, Әхмәт Исхак һ.б. язучылар катнашалар. Бу әдәби төркемнәрне чын мәгънәсендә «оешмалар» дип атау читен, билгеле. Үз вакытында «әдәби күмәкләр» дип йөртү аларның характерын шактый төгәл гәүдәләндергән, чөнки аларда катнашучыларның саны да аз һәм идея-эстетик декларацияләре дә формалашмаган һәм каршылыклы иде», – дип яза татар әдәбият галиме һәм тәнкыйтьчесе, филология фәннәре докторы, ТАССРның атказанган фән эшлеклесе Гали Халит (1915-1992) [9, б. 107]

Вакытлы матбугатта язучыларны бердәм әдәби оешмага берләштерү кирәклеге турындагы сораулар торган саен ешрак күтәрелә бара. Г. Нигъмәти совет язучылары җәмгыятен төзергә тәкъдим итә, Г. Ибраһимов аны төзүнең төп принципларын формалаштыра. 1927 елның 9 февралендә Советлар Союзы Коммунистлар партиясе өлкә комитетының матбугат бүлегендә Язучылар оешмасын төзү турында карар әзерләү буенча комиссия (Г.Ибраһимов, Ф. Бурнаш, Г. Толымбайский, Г. Нигъмәти) барлыкка килә. 1928 елның 5 маенда татар язучылары җәмгыяте оештырыла һәм ул 1932 елның февраленә кадәр эшли. Татар пролетар язучылар Ассоциациясе (ТАПП) 1928 елның 27 сентябреннән 1932 елның 16 маена кадәр яшәп килә һәм Бөтенсоюз Коммунистлар партиясе (большевиклар) Үзәк Комитетының «Әдәби-сәнгать оешмаларын үзгәртеп кору турында» Карары чыккач таратыла. Крестьян Язучылары Берлеге, соңрак Колхоз-Пролетар Язучылар берлеге дип үзгәртелә. Кызыл Армия һәм флот әдәби берләшмәсенең (ТАТЛОКАФ) татар секциясе 1930-1932 елларда эшли [8]. Әлеге иҗади оешмалар эшчәнлегендә Казан университеты студентлары да катнашкан булуы аңлашыла.

Бөек Ватан сугышы башланганнан соң университет укытучыларын, аспирантларын, студентларын һәм хезмәткәрләрен армиягә мобилизацияләү гамәлгә ашырыла. 1941 елның 1 июнендә комсомол исәбендә торган 1198 комсомолецтан 1941 елның 1 октябренә 600 кеше генә калган. 1941-1942 нче уку елының беренче семестрында укулар бөтенләй туктатыла, аннан соңгы елларда да студентлар саны җитмәгәнлектән, университет ябылу алдында кала. 1942 елга инде кайбер факультетларның 3-4 курс дәресләрендә 1-2 студент катнаша алган. 1943 елга университетта 1941 ел белән чагыштырганда 3 тапкыр азрак студент белем ала (1280 кеше һәм 406 кеше). 1945 елның июленә КДУ студентлары саны нибары 783 кеше тәшкил иткән [10].

1944 елның 9 августында ВКП(б) Үзәк Комитеты «Татар партия оешмасында массакүләм-сәяси һәм идеологик эшнең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында» Карар кабул итә [11]. Бу карарда Татар автономик совет социалистик республикасында язучылар һәм сәнгать эшлеклеләре эшенә канәгатьләнерлек җитәкчелек итмәү, мәдәният оешмалары репертуарына контроль җитмәү һәм интеллигенциягә идея-сәяси тәрбия бирү буенча эшнең начар булуы, нәтиҗәдә республикада татар халкы тарихын, шулай ук әдәбият һәм сәнгатьне яктыртуда җитди хаталар килеп чыгуы күрсәтелә [12]. Бу хаталарны төзәтү һәм милли сәясәтне көйләү өчен җитди адымнар ясарга кирәклеге ачыклана. Шундый адымнарның берсе булып, Казан университетында татар бүлеге ачылу саналырга хаклы.

Шул рәвешле, 1944 елда Казан университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге оештырыла, анда киң профильле галим-филологлар, гуманитар белгечләр, шулай ук татар теле һәм әдәбияты укытучылары әзерләнә башлый [13, б. 102]. Бүлек җитәкчесе итеп билгеләнгән доцент Рабига Афзал кызы

Хәкимова [14, б. 134] тиз арада татар телен һәм әдәбиятын югары дәрәҗәдә укыта алырлык педагог-галимнәр коллективы җыюга ирешә һәм беренче курска ун студент кабул ителә. Шунысы кызыклы: кабул итү вакытында абитуриентларның белем ягына гына түгел, ә иҗади мөмкинлекләренә дә зур игътибар бирелә [13, б. 103]. Әлеге бүлекнең татар дөньясы үсешенә керткән өлеше турында татар халык шагыйре Равил Фәйзуллин болай дип яза: «1944 елда булган позитив ике вакыйганы да искә алып үтик: шул ук август аенда Татарстанның крайны өйрәнү музее каршында әдәбият музее оештыру, Ш. Камалның квартира-музеен булдыру турында РСФСР Халык Комиссарлары Советы карары һәм икенчесе – Казан дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачылу. Татар әдәбияты, мәдәнияте тарихында бүлекнең әһәмияте әйтеп бетергесез. Бүгенге әдәбиятны тудыручылар, нигездә, университеттан, шушы бүлектән үсеп чыккан язучылар» [15, б. 11]

Татар бүлеге оешуының беренче айларыннан ук бирелдә иҗади түгәрәк эшли башлый, агитбригада чыгышлары оештырыла, «Әдәби сүз» дип аталган стена газетасы дөнья күрә. Әлеге бүлекне тәмамлаган күп кенә иҗади шәхесләр (Ибраһим Нуруллин, Нурихан Фәттах, Мирфатыйх Зәкиев, Мансур Хәсәнов, Равил Фәйзуллин, Аяз Гыйләҗев, Гариф Ахунов, Марсель Әхмәтҗанов, Рәдиф Гаташ, Хатыйп Миңнегулов, Азат Әхмәдуллин, Марсель Бакиров, Вахит Хаков, Гомәр Саттаров, Фәһимә Хисамова, Флёра Сафиуллина, Фазыл Фәсиев һ.б.) соңыннан татар халкының күренекле фән һәм мәгариф, мәдәният эшлеклеләре булып китәләр, университетта укытырга калалар [16, б. 213]. Сугыш алды репрессияләренә эләгеп, юкка чыгарылган, яу кырларында һәлак булган татар зыялылары урынына сугыштан соңгы ачлык-ялангачлык арасыннан яктыга – мәгърифәткә омтылган яңа катлам татар интеллигенциясе барлыкка килә. Аның формалашуына зур өлеш керткән иҗади түгәрәк – «Әллүки»нең дә тарихы озын һәм катлаулы.

Татар бүлегендә гөрләп эшләгән түгәрәк егерме елдан артык исемсез, бары «әдәби түгәрәк» дип кенә атап йөртелгән. «Хрущёв җепшеклеге» вакытында баш төрткән сүз иреге әдәби барышка да үзгәрешләр алып килә. Казан университетында алтмышынчы елларда укыган татар студентлары әдәбият дөньясына үзләре бер «дулкын» булып, ургылып килеп керәләр. Бу вакытта лекцияләрне татар халкының атаклы мөгаллим-педагоглары Хатип Госман, Латыйф Җәләй, Якуб Агишев, Мансур Габдрахманов, Ибраһим Нуруллин, Диләрә Тумашева, Гаяз Ишмөхәммәтовлар алып барган. 1965 нче елда татар филологиясенә укырга килгән ике егет – Зөлфәт Маликов һәм Мөдәррис Әгъләмов әдәби утырышларның иң дәртле, актив оештыручыларыннан булалар. Түгәрәкнең исемсез йөрүе, күрәсең, алар күңелендә ризасызлык уяткан. Һәм, озак уйлап тормый, татар халкының бишек җыры булган «Әллүки»не 1967 нче елда түгәрәк исеме буларак игълан итәләр. Исеме җисеменә туры килә: «Әллүки», чын мәгънәсендә, яшь иҗатчыларны тәрбияли торган, аларга канат куя, үстерә торган бишек булып әверелә. Бүгенге көндә татар халкының сөекле уллары-кызлары Роберт Миңнуллин, Зиннур Мансуров, Мөдәррис Вәлиев, Фәйрүзә Мөслимова, Галимҗан Гыйльманов, Рафис Корбан, Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла, Рифә Рахман, Илсөяр Иксанова һәм башка бик күпләр – әлеге бишектә тәрбияләнеп, иҗат дөньясында үз юнәлешен булдырган әдипләр.

Аяз Гыйләҗевнең тууына 80 ел тулу уңаеннан Алексей Егоров тарафыннан оештырылган әңгәмәдә Туфан Миңнуллин болай дип билгели: «Түгәрәк эшендә студентлар да катнашты, аларның күбесе соңыннан танылган шагыйрь булдылар. Аларга Аяз Гыйләҗев иҗаты, аның компромисска бирелмәве ошый иде, һәм алар аны, әлбәттә, очрашуга чакыралар иде. Мин дә берничә тапкыр түгәрәк утырышында булдым. Хәсән Туфаннан, Сибгат Хәкимнән, Аяз Гыйләҗевтан башка нинди утырыш?! Студентлар белән очрашуга исемнәре бүген дә татар әдәбиятының горурлыгын тәшкил иткән язучылар килә иде...» [17, б. 134] Аяз Гыйләҗевнең әдәби түгәрәккә йөрүе турында галимә М.М. Хәбетдинова мәкаләсендә дә басым ясала: «А.М. Гыйләҗев беренче тапкыр Венгрия темасына геройның Казан университетында укуын тасвирлаганда мөрәҗәгать итә. И. Батуллин университетның тарих-филология факультетындагы әдәби түгәрәк утырышларына йөри, анда студентлар, гадәттә, бер-берсенә үзләренең иҗади әсәрләрен укый, теге яки бу әдәби яңалыклар турында фикер алыша, язучылар белән очраша. Әдәби түгәрәкнең һәр әгъзасы повестьның төп героеның күзе белән күренә һәм бәяләнә» [18, б. 105-106].

Түгәрәкнең җитәкчесе алышынып торган. Гадәттә, студентлар үзләре арасыннан иң актив, иҗат итә торган, оештыру сәләте булган студентны староста итеп сайлаганнар, ә татар бүлеге укытучылары арасыннан бер укытучы җитәкче-куратор буларак билгеләнгән. «Әллүки» тарихы турында сөйләгәндә, озак еллар дәвамында университетта әдәбият фәне тармакларын укыткан, үзе дә «Әдәби сүз» газетасында иҗат юлын рәссам буларак башлаган Марсель Хәернас улы Бакиров исемен атыйлар. Марсель аганың «Әллүки» яшәешенә керткән өлеше әйтеп бетергесез зур. Төрки шигырь төзелешен фәнни яктан өйрәнгән шигъри күңелле галим һәрвакыт яшь шагыйрьләр иҗаты белән кызыксына, үзенең киңәшләрен бирә, юнәлеш күрсәтә. Ул баш мөхәррир чагында «Әдәби сүз» стена газетасы университет күләмендә уздырылган ярышта беренче урынга чыгып, аннан соң Казан шәһәрендә үткән вузара ярышта да алдынгылыкны яулый.

XX гасырның 70-90 нчы елларында һәм XXI гасыр башында «Әллүки» әдәби түгәрәген татар бүлегендә эшләгән язучы-галимнәр әйдәп алып баралар. Мөдәррис Вәлиев, Мөхәммәт Мәһдиев, Галимҗан Гыйльманов, Рифә Рахман әдәби остаханәсе аша дистәләрчә әллүкиче иҗат дөньясына килеп керә, күренекле язучы-шагыйрьләр булып җитешәләр. Бу еллардан Рөстәм Сүлти, Рәмис Аймәт, Резидә Әхтәмова (әдәби тәхәллүсе Җәмилә), Алмаз Гыймадиев, Айдар Минһаҗев, Чулпан Әхмәтова, Гамилә Рәхмәтуллина һ.б. исемнәр «Әллүки» елъязмасына уелып кала.

Шау-шулы 90 нчы еллар ахырында «Әллүки» берара тынып кала. Әллә җәмгыятьтә барган икъдисадый-сәяси тетрәнүләр әдәби барышка тискәре йогынты ясый, әллә инде зур күтәрелеш алдыннан түгәрәк хәл җыя. Бу күтәрелеш исә үзен озак көттерми: 2000 нче елларда университетта иң зур факультетларның берсенә әйләнгән Татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультетына үзгәртеп кору чорында туган балалар укырга килә башлый. Болар – хөр фикерле, милли җанлы, белемле укучылар була. Дөньяны киңкырлы күзаллау белән бергә, күбесенең күңелендә әдәбиятка тартылу яши. Йолдыз Миңнуллина, Луиза Янсуар, Ленар Шәех – нәкъ менә шушы чорда шушы мохиттә белем алган шәхесләр. Факультетта татар рухы кайный: атаклы «Каз канаты» бию түгәрәге, «Татар хоры» эшли. Галимҗан Гыйльманов җитәкчелегендә 2 курс студенты Ленар Шәех (хәзерге вакытта танылган шагыйрь, журналист, Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире) 2003–2007 елларда «Әллүки» түгәрәгенең эшен кабаттан торгызып җибәрә, «Әдәби сүз» стена газетасы урынына типография юлы белән басылган һәм университет студентлары арасында таратылган «Тәрәзә» газетасын гамәлгә куя, 2003–2008 елларда аның баш мөхәррире була. Ленар Шәех ул вакытларны түбәндәгечә искә ала: «XXI гасыр башында яңадан оешкан «Әллүки» әдәби иҗат берләшмәсенең иң беренче утырышы узган көнне төгәл хәтерлим: 2003 елның 24 сентябре иде ул. Татар студентларының «Тәрәзә» газетасын оештыру һәм чыгара башлау мәсьәләсе дә шул җыелышта хәл ителде. Октябрь аенда инде өр-яңа татар телле яшьләр матбугатының тәүге саны дөнья күрде. Күләме дә дүрт кенә бит, тиражы да илле генә данә, ләкин ул – тарихи сан, татар әдәбиятына килгән яңа буынның киң җәмәгатьчелеккә үз сүзен җиткерүе иде.

«Тәрәзә»гә материаллар туплау, яңалыклар җыю, әллүкичеләргә заказ биреп, мәкаләләр һәм интервьюлар яздыру, килгән язмаларны редакцияләү... – һәммәсе дә мин фәкыйрегез җаваплылыгында булды. Беренче саннарны биткә салган компьютерчы егет Флорит Заһретдиновтан программаны тиз отып алдым, бераздан бу эш белән дә үзем шөгыльләнә башладым.

Газета саннан-санга яхшырды, язучылар саны артты, күтәрелгән темалар-проблемалар киңәйде. Гади ксерокста тиражланган газетаның күләме егерме биткә җитте, ул университет типографиясендә басыла башлады, тиражы 999 данәгә күтәрелде. Дөрес, аерым саннар чынлыкта 2 мең белән дөнья күрде, бу аның таралыш даирәсен киңәйтү максатыннан эшләнде.

«Тәрәзә»не әзерләү күп вакытны алганлыктан, аерым бер очракларда безгә, «Әллүки» егетләренә, төп бина белән килештереп тә, рөхсәтсез дә, 11 нче катта урнашкан факультетның компьютер бүлмәсендә эш төннәре үткәрергә туры килде.

2004 елдан «Шигъри Сабантуй» бәйгесе оештырыла башлау газетаның укучыларын арттырды. Аның һәр саны Татарстан һәм Башкортстан югары һәм урта махсус уку йортларына җибәрелә башлады, Казанда студентлар яши торган тулай торакларда таратылды. «Шигъри Сабантуй» исә, Татарстан Язучылар берлеге белән бергәләп уздырыла

торган, иҗади татар студентларын бергә туплаган региональ бәйгегә әверелде. Татарстан китап нәшрияты ярышның даими иганәчесе булды.

Минемчә, «Әллүки»не яңадан оештыру бик дөрес һәм вакытлы гамәл булды. Аның ярдәмендә меңьеллык татар әдәбияты үзенә дәвамчылар тәрбияләде, дистә еллар өзеклектән соң, өр-яңа буын әдәби мәйдан буйлап атлап кына түгел, ә киләчәккә карап, колачын киң итеп ачып йөгереп үк китте».

Әдәби иҗат түгәрәкләренең эш форматы, гадәттә, берничә юнәлешне – яшь иҗатчылар бер-берсенең әдәби әсәрләрен укып-тикшереп, анализ ясау, тәнкыйть утырышлары үткәрү; танылган әдипләр, шәхесләр белән очрашу; үзара сөйләшеп утыру, тормыш, уку һ.б. темаларга фикер алышу; театр-концертларга бару, соңыннан аларга бәя бирү һ.б. эш-гамәлләрне үз эченә ала. Шагыйрь Булат Ибраһим «Әллүки» утырышларын түбәндәгечә сурәтли: «"Әллүки"дә яшь язучыларның иҗатларын анализлап фикер алышу оештырылган көннәр иң кызыклылары иде. Монда язучының психологик яктан нык булуы кирәк, чөнки күп кенә яшь язучылар тәнкыйтьне кабул итәргә әзер булмыйлар. Күз яшьләре белән елаган иҗатчыларны да күргән чакларым булды.

Ике-өч айдан соң мине – 1 курс студентының иҗатын тикшерүгә куйдылар. Ул вакытта утырышлар хәзерге КФУ бинасының 2 нче корпусында 11 нче каттагы аудиториядә була иде (Бу елларда Татар филологиясе факультеты 11 катта урнашкан иде). Курка-курка кереп утырдым. «Әллүки»нең кураторы Галимҗан Гыйльманов минем шигырьләрне укый. Минем туган авылыма багышланган шигырьне тикшергәннәре хәтеремдә калды. Шунда кайсыдыр: «Әлеге шигыреңдә синең туган авылың исемен минем туган авылым исеменә үзгәртеп куйсак, укучы бернәрсә дә сизмәячәк», – дип куйды.

Мин уйланып калдым. Чыннан да, шулай иде. Бу утырыш миңа шигырьнең оригинальлегенә, үзенчәлекле булуына карата игътибарны арттыру өчен мәңгелек дәрес булды».

Бу елларда «Әллүки» татар факультеты студентларын гына түгел, башка уку йортларыннан да студентларны үзенә туплый, Татар дәүләт гуманитар-педагогик университетының «Илһам», Алабуга дәүләт педагогик университетының «Шәкертләр», Башкортстандагы «Акчарлак» һәм «Шоңкар» әдәби иҗат түгәрәкләре белән бәйләнешкә кереп, фикердәшләрен таба, Идел-Урал төбәге студентларының «Шигъри Сабантуй» дигән иҗат бәйгесен оештыра. Ленар Шәех, Лилия Гыйбадуллина, Рифат Сәлах, Айсылу Имамиева, Рөстәм Галиуллин, Лилия Закирова, Айдар Җамал кебек әллүкичеләрнең китаплары дөнья күрә, аларның күбесе соңрак Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителә.

2006 нчы елда «Тәрәзә» газетасы республика күләмендә уздырылып килгән «Ел студенты» бәйгесенең «Иң яхшы студентлар басмасы» номинациясендә лауреат исеменә лаек була, 2007 нче елда университетта үткән «Ел студенты» конкурсының «Иң яхшы студентлар газетасы» номинациясендә җиңү яулый. Татарстан китап нәшрияты, әллүкичеләрнең иң яхшы әсәрләрен туплап, ике тапкыр «Әллүки» дигән җыентык бастырып чыгара. 2008 нче елдан башлап, түгәрәкнең җитәкчесе буларак, филология фәннәре кандидаты, татар теле белеме кафедрасы доценты, язучы, шагыйрә, телевизион фильм сценарийлары авторы Халисә Ширмән билгеләнә.

Әдәби иҗат түгәрәкләре турында сөйләгәндә, һичшиксез, Казан дәүләт гуманитар-педагогика университетында озак еллар эшләп килгән «Илһам» түгәрәге эшчәнлеген дә күрсәтү мөһим. Революциягә кадәрге чорда Казан губернасы шәһәр гимназияләре өчен укытучыларны Казан университеты тарих-филология һәм физика-математика факультетларында, ә халык училищелары укытучыларын урта уку йорты булган Казан укытучылар институты әзерли. 1918 елда мәгариф буенча Беренче Бөтенроссия съезды узганнан соң, аның карары нигезендә барлык урта педагогик уку йортлары югары уку йорты статусын алганнан соң, Казан укытучылар институты педагогика институты итеп үзгәртелә. 1925 елдан институтның Көнчыгыш бүлеге милли бүлекләргә бүленә: башта татар һәм чуваш милли-лингвистик бүлекләренә, 1926 елдан аларга вот һәм мари бүлекләре өстәлә [19, б. 73]. Татар теле һәм әдәбияты кафедрасы оештырылганнан соң, биредә әдәби түгәрәк эшли башлый, газета чыга. 1944 елга кадәр ул ил территориясендә татар теле һәм әдәбияты укытучылары әзерләгән бердәнбер бүлек була. Әлеге елларда институтта укыган педагог Кудашев Габделхак Хафиз улы үзенең истәлекләрендә бу эштә

Гадел Кутуй һәм Хәсән Туфанның актив катнашуы турында яза: «Егерменче елларны Казан дәүләт университетының зур бер аудиториясендә Галимҗан Ибраһимов, Газиз Гобәйдуллин, Гали Рәхим һәм башка тел, тарих белгечләренең катнашы белән еш кына гыйльми җыелышлар үткәрелде. Бу җыелышларда шул чор өчен актуаль мәсьәләләр, фәнни яңалыклар буенча докладлар ясала, фикер алышулар була иде. Көнчыгыш педагогия институтындагы татар студентларының күбесе бу җыелышларга йөрделәр.

1924 елның көзендә Көнчыгыш педагогия институтында беренче тапкыр татар телендә стена газетасы чыга башлады. Бу газетаны чыгаруда Хәсән белән Кутуй да актив катнаштылар. Кутуйның тәкъдиме буенча, газетага «Укы-төзе» исеме бирелде. «Укы-төзе» газетасы институтның төрле бүлекләрендә укучы татар студентларын оештыруда, аларны җәмәгать эшләренә тартуда әһәмиятле фактор булды. Институттагы татар студентларының күпчелеге газетаны оештыруда, аңа язышуда еш катнашты. Газета редакциясенә кульъязмалар күп керә иде, аларны грамматик һәм стилистик яктан эшкәртү, башлыча, Хәсән белән Кутуй тарафыннан башкарылды» [20, б. 180].

Танылган әдәбият галиме, педагог, филология фәннәре докторы, профессор Фоат Галимулла улы Галимуллин «Илһам канатларында» дип аталган мәкаләсендә Көнчыгыш педагогия институтында әдәби түгәрәкләрнең башлангыч чорын тасвирлый, аларның эшчәнлеген күрсәтә: «1926–1929 елларда татар бүлеге үзенең иҗтимагый-сәяси һәм әдәби журналын чыгара. Ул «Яшь педагог» дип атала. Басмада Г. Кутуй, Г. Кашшаф, Ә. Еники, Ф. Даутов, М. Богданова, М. Кашафетдинова үз әсәрләрен бастыра. 1928-1929 уку елында, мәсәлән, бирелгәге фәнни-әдәби түгәрәктә иллегә якын студент шөгыльләнгәне мәгълүм. 1926-1927 уку елында институтта Һ. Такташ, Г. Бакир белем ала. Һади Такташ кулларына иҗат каләме алган яшьләр белән даими очраша, аларны үзенең әсәрләре үрнәгендә рухландыра. Г. Кутуйның да әлеге түгәрәктә еш чыгыш ясавы билгеле. 1932-1933 уку елыннан биредә булачак шагыйрь Хәбра Рахман укый. Аны әдәби түгәрәк җитәкчесе итеп сайлыйлар» [3].

Әдәби түгәрәкнең XX гасыр уртасында чыккан «Яшьлек тавышы» дип аталган кульъязма альманахы да булуы мәгълүм. Озак еллар түгәрәк белән җитәкчелек иткән педагог Мәдинә Шәйхи кызы Җәләлиева 1967 нче елда түгәрәк эшчәнлеге, аның тарихы турында «Татарстан яшьләре» газетасында «Безнең түгәрәк» дип аталган мәкалә бастыра [21]. 1974 нче елдан түгәрәк белән ул вакытта яшь укытучы Фоат Галимуллин җитәкчелек итә башлый һәм кафедра мөдире Фәрит Хатыйпов белән берлектә түгәрәкнең исемен «Илһам» дип атарга һәм иҗат берләшмәсе буларак тәкъдим итәргә карар кылына. Бу елларда укыган студентлар арасыннан Рафис Гыйззәтуллин, Зиннур Хөснияр, Марат Закир кебек танылган язучылар үсеп чыга. Соңрак иҗат берләшмәсе белән җитәкчелек итү үзе дә шагыйрь булган Әмир Гобәй улы Мәхмүдовка тапшырыла. Ул Рәшит Фәтхерахманов, Роза Зайцева, Фәридә Фәйзрахманова, Венера Салахова, Рухия Ахунҗанова, Зөлфия Хәмзина, Раушания Сәхапова, Нәфисә Гыйззәтуллина кебек яшь шагыйрь һәм язучылар иҗаты хакында «Татарстан яшьләре» газетасында мәкалә дә бастыра [22].

2005 елда Казан дәүләт педагогика университеты һәм Татар дәүләт гуманитар институты берләшү процессы башлана һәм яңа барлыкка килгән структура «Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты» дип атала башлый. Татар дәүләт гуманитар институтында студентларның «Дастан» исемле әдәби иҗат түгәрәге һәм ун биттән торган «Дастан» дигән иҗади-мәгълүмати газета эшләп килгән [23].

Уку йортлары кушылу нәтиҗәсендә бу түгәрәкләр дә берләшә һәм алга таба әдәби иҗат берләшмәсенең эшчәнлеге аспирантлар Рамил Ханнанов һәм Марат Миндубаев кулына күчә, студентлар һәм мәктәп укучылары өчен «Илһамлы каләм» дигән иҗади конкурс оештырыла, «Раушан» газетасы чыгуын дәвам итә. Бу елларда Рүзәл Мөхәммәтшин, Рүзәл Әхмәдиев, Динара Әхмәтова, Зилә Фәсхиева кебек талантлы яшьләр дөньяга үзләрен таныта башлый. Студентларның иҗаты өч китаптан торган «Илһам канатында» дип аталган әдәби җыентыкта урын ала.

2010-2011 нче еллар милли кадрлар тәрбияли торган уку йортларына тагы да зуррак үзгәрешләр алып килә. Бу елларда Казан дәүләт университеты һәм Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты федераль оешмага берләшкәннән соң, «Әллүки» һәм «Илһам» түгәрәкләре һәм алар чыгара торган «Тәрәзә» һәм «Раушан» газеталары да кушылып, «Әллүки» әдәби иҗат берләшмәсе һәм аның

газетасы «Раушан» буларак эшләп китәләр. Ел саен үткәрелә торган «Шигъри Сабантуй» һәм «Илһам канатында» бәйгеләре студентлар арасында гына түгел, мәктәп укучылары арасында да көтеп алынган тантанага әйләнә. Аеруча әллүкичеләрнең «Калеб» оешмасы үткәргән «Яңа дулкын – 1» һәм «Яңа дулкын – 2» перформанслары матбугат битләрендә төрле бәхәсләр уята [24]. Бу елларда әдәбият мәйданында Булат Ибраһим, Фәнил Гыйләҗев, Алмаз Мансуров, Руфинә Габдрахманова, Эльмира Камаева, Айгөл Абдрахманова, Чулпан Гобәйдуллина, Светлана Гыйләҗева, Илсөя Галиәкбәрова, Алинә Галиева, Гүзәл Закирова (әдәби тәхәллүсе Гүзәлә), Ләйлә Хәбибуллина, Зилә Сабитова, Алсу Сәлахова, Гелүсә Шиһапова, Энже Хөсәенова кебек яңа исемнәр мәгълүм була, аларның иҗаты «Илһам канатында», «Дәвам», «Ак юл» җыентыкларында дөнья күрә, төрле иҗади конкурсларда әллүкичеләр ел саен утызга якын призлы урыннар яулыйлар. Бүгенге көндә танылып килә торган яшь иҗатчылар Ильяс Хаҗиев, Ихтыяр Кыямов, Айзилә Абдрахманова, Гөлназ Әхмәдиева, Гөлинә Фәрхуллина һ.б. «Әллүки»нең дәвамчылары булып тора.

Казан федераль университеты Габдулла Тукай исемендәге милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбенең татар теле белеме кафедрасы бүлмәсендә бик кадерле бер ядкяр саклана. Совет елларында һәркемнең өендә булган, бәрхет тышлыгыннан бераз нафталин исе аңкып торган калын битле альбом ул. «Әллүки» түгәрәге альбомы. Бу альбомда әдәби түгәрәкнең «Әллүки» исемен алуын билгеләп үтү вакыйгасы, әлеге чарага килгән күренекле әдипләрнең кул тамгалары һәм килер буын әллүкичеләргә аталган сүзләрен саклана. 1987 нче елда шул вакыттагы әллүкичеләр – Люция Шәрәфиева, Света Заһриева, Әлфия Сафина һәм Филиза Сәлахова язып куйган: «Без 24 апрель көнне «Әллүки» әдәби түгәрәгенә «Әллүки» дип исем бирелүгә 20 ел тулуны билгеләп үттек. 12 март 1985 елда «Әллүки» түгәрәге оештырылуга 40 ел тулуын билгеләп үткән идек. Безнең түгәрәк татар бүлеге ачылганнан бирле яшәп килә икән инде». Димәк, 2024 нче елда татар бүлеге һәм әдәби иҗат түгәрәге «Әллүки» оешуга 80 ел тула.

*« ”Әллүки” нең яшен сорамагыз –*
*Халык белән бергә туган ул:*
*«Әллүки» ул – зәңгәр күзле Такташ,*
*Һәм ак чәчле Хәсән Туфан ул... »* – дип язган бу альбомга 26 яшьлек әллүкиче Ләбиб Лерон – бүгенге көндә танылган язучы, шагыйрь, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (2002), Муса Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты (2007), Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (2022).

Бүгенге көндә «Әллүки» – милли әдәби традицияләрне саклау һәм үстерүгә юнәлтелгән берләшмә. Иҗади кичәләр, иҗат остаханәләре, Татарстан Республикасы Язучылар берлегенең әдәби салоннарына бару, тәнкыйть утырышлары, төрле иҗади ярышларда һәм проектларда катнашу, студентлар язган сценарийларга нигезләнеп, кыска метражлы фильмнар төшерү, мәктәп һәм гимназия укучылары белән волонтёрлык эше «Әллүки» эшчәнлегенең форматын тәшкил итә.

Әдәби түгәрәкләр тарихи-әдәби процессны үстерүдә һәм әдәби чорны формалаштыруда мөһим роль уйный. Түгәрәкләрдә һәм әдәби салоннарда әдәби һәм иҗтимагый идеяләр ассимиляцияләнә, әдәби кыйммәтләр формалаша, кайбер очракларда җәмгыятьтә урнашкан негатив карашларга каршы әдәби көрәш тактикасы хәл ителә [25]. Түгәрәкләр һәм салоннар әдәби эшчәнлек өлкәсенә генә түгел, музыкага, рәсем сәнгатенә, фәлсәфәгә дә зур урын бирә. Нәкъ менә шушы бергәлекләрдә эшчәнлекнең төрле өлкәләре вәкилләре арасында белем, тәҗрибә, фикер алышулар уза (мәсәлән, Казанда Гүзәл Сәгыйтова җитәкчелегендә эшчәнлек алып барган «Калеб» оешмасын күрсәтергә мөмкин).

Шул ук вакытта кайбер галимнәр әдәби иҗат түгәрәкләренең эшчәнлегенә артык әһәмият бирү белән килешмиләр. Мәсәлән, «Әллүки» иҗат берләшмәсе җитәкчеләренең берсе, галимә һәм танылган язучы, тәнкыйтьче, шагыйрә Рифә Рахман фикеренчә, Казан университетында үзе алып барган әдәби тәнкыйть, иҗади лаборатория дәресләре студентларның әдәбиятка тартылуына китергән, ә түгәрәк эшчәнлеге исә мондый эффектны бирә алмый. Әдәбият галиме, прозаик Галимҗан Гыйльманов исә, киресенчә, «мин “Әллүки” иҗат берләшмәсе җитәкчесе булып эшләгәндә, еш кына без студентлар белән җыелып, төрле темаларга сөйләшеп утыра идек. Аларның шулай үзара җыелып, аерым бер темага сөйләшүләре дә студентларны берләштерә, әдәбиятка тарта,

бер-берсенең иҗатына кызыксыну уята» дип күрсәтә.

Әдәби түгәрәкләрнең әһәмияте әдәбият галимнәре Таһир Шәмсегали улы Гыйләҗев һәм Әлфәт Мәгъсум улы Закирҗанов хезмәтләрендә дә еш искә алына. Мәсәлән, Габдулла Тукай турында язганда, Т.Ш. Гыйләҗев шагыйрьнең әдәби мохитенә аеруча басым ясый: «Кайчакта гомуми тенденциягә бирелеп, татар мәктәп-мәдрәсәләрендәге Тукайның әдәби мохитен, Җаек, Казан шәһәрләрендәге әдәби-мәдәни хәятен кечерәйтеп күрсәтү күзәтелә. Шагыйрьнең әдәби абруен, шагыйрьлек дәрәҗәсен күтәрүдә «Мотыйгыя» мәдрәсәсендәге әдәби мәҗлесләр, Казандагы әдәби кичәләр, Шәрык клубы әһәмиятле роль уйнаган» [26].

Ә.М. Закирҗанов хәзерге вакытта әдәби тәнкыйть өчен дә түгәрәк өстәлләрнең, сөйләшүләрнең кирәклеген ассызыклый: «Мондый чаралар, әлбәттә, әдәбиятыбызга кагылган рухи-эстетик фикерне җанландыра, сафта күренгән азмы-күпме кадрларны шушы юнәлештә уйланырга һәм үзләренең фикри-эстетик куәтләрен матбугатта сынап карарга этәрә» [27, б. 5].

Әдәби түгәрәкләр һәм берләшмәләр белән берлектә, Казан университетында фән белән кызыксынган яшьләр өчен иҗади фәнни түгәрәкләр дә эшләп килә. Мәсәлән, 2000 елларда ук оешкан «Белем сукмаклары» түгәрәге бүгенге көндә татар теле белеме кафедрасында «Татар теле белеменең актуаль мәсьәләләре» исеме белән үзенең эшчәнлеген дәвам итә. Түгәрәк җитәкчесе филология фәннәре кандидаты, татар теле белеме кафедрасы доценты Һадиева Гөлфия Камил кызы студентлар белән берлектә татар теле һәм әдәбиятының актуаль мәсьәләләрен өйрәнәләр [28].

2023 елда татар әдәбияты кафедрасы доценты Гайнуллина Гөлфия Расил кызы җитәкчелегендә фәнни түгәрәк буларак оешкан «Рухият» түгәрәге студентлар арасында татар әдәбияты, әдәбият гыйльмияте хакында сөйләшүләрне актуальләштерүгә йөз тота. Эшли башлаган елны ук түгәрәк әгъзалары «Казан утлары» журналының «Китап күзәтү» рубрикасында биш мәкалә белән чыгыш ясадылар, Казан федераль университеты күләмендә оештырылган конференцияләрдә, бәйгеләрдә җиңүләр яуладылар. Түгәрәк утырышларында кырык студент катнаша. Киләчәктә түгәрәк эшендә яшьләрне гыйльмияткә тарту, пропагандалауга әһәмият биреләчәк. Аерым алганда, әдәбият тарихындагы ак тапларны өйрәнүгә, онытылган исемнәрне барлау, популярлаштыруга игътибар биреләчәк.

**Төп нәтиҗәләр**

Казан университетында милли әдәби иҗат берләшмәләре һәм түгәрәкләре барлыкка килүнең үзенчәлекле тарихы бар. Биредә татар телле әдәби түгәрәкләр татар теле фундаменталь рәвештә укытыла башлагач, ягъни XX гасырның беренче яртысында барлыкка килеп, берничә тапкыр үзгәргәннәр һәм бүгенге көнгә кадәр үз эшчәнлекләрен дәвам итәләр. Шундыйлардан «Әллүки», «Илһам», «Дастан», «Рухият» түгәрәкләрен һәм берләшмәләрен күрсәтергә мөмкин. Еллар дәвамында аларның эшчәнлеге дулкын сыман күтәрелеп һәм сүрәнләнеп торган. Әдәби берләшмәләр һәр катнашучының шәхси иҗаты үсешенә зур йогынты ясый һәм шул ук вакытта берләштерә дә, чөнки уртак эш формасы, иҗат методлары моңа кадәр автор кулланмаган төрләрне активлаштырырга ярдәм итә. Берләшмә утырышларында шигърият, драма һәм проза әсәрләренең классик үрнәкләре белән танышу, яшь иҗатчыларның шәхси иҗатында куллана торган алымнар турында фикер алышу, яшь авторлар тарафыннан язылган әсәрләрнең текстларын җентекләп уку һәм тәнкыйть-анализ ясау әдәби иҗат үсешенә мөмкинлек бирә. Уртак иҗади эш – әдәби-тематик тренинглар, аралашуның уен формасы, конкурслар һәм ярышлар, гомуми темага өй эшләре башкару да яшьләрне берләштерә һәм иҗатка юл ача.

Әдәби берләшмәләр аерым бер авторга гына түгел, тулаем җәмгыять үсешенә дә йогынты ясый, автор һәм милләт арасындагы бәйләнешне тәэмин итә, милли мәдәниятнең тулы бер катламы буларак, әдәбиятның әһәмиятен саклап калуга ярдәм итә.

Тикшеренү эше ФПСП-2/24 темасы кысаларында башкарылды.

**Әдәбият**

1. Левкина Л. И. Социально-историческая роль сообществ: монография / Л. И. Левкина. – Москва: Русайнс, 2020. – 181 с.

2. Валеев Р. М., Тихонова М. С. Первый литературный кружок в г. Казани конца XVIII-

начала XIX вв // Вестник КазГУКИ. 2014. №3. С.39–44.

3. Галимуллин Ф.Г. Илһам канатларында // Безнең мирас. 2012. № 2. Б. 3-10. URL: https://beznenmiras.ru/news/edebi-miras/ilham-kanatlarynda (дата обращения: 19.07.2024).

4. Ширмән Х. Әллүкиле еллар / Х. Ширмән // Безнең мирас. 2019. № 4. Б. 74–78.

5. Demirkaya A.E. Kazan'daki edebî mahfiller: salon söyleşilerinden edebî topluluklara // İdil-Ural Araştırmaları Dergisi, 2022; 4 (1): 31–53.

6. Кузьмина Х.Х., Нуриева Ф.Ш. Казан университетында татар теле тарихы фәнен өйрәнү // Tatarica. 2024. № 1 (22). С. 7–-25.

7. Вишленкова Е.А., Малышева С.Ю., Сальникова А.А. Terra Universitatis: Два века университетской культуры в Казани. – Казань: Казанский государственный университет им. В.И. Ульянова-Ленина, 2005. – 500 с.

8. Гиззатуллин Н.Г. Литературные кружки и объединения в РТ // Онлайн-энциклопедия Tatarica. – Электронный ресурс. – URL: https://tatarica.org/ru/razdely/istoriya/novejshee-vremya/literaturnye-kruzhki-i-obedineniya-v-rt (дата обращения: 19.07.2024)

9. Халит Гали. Татар совет әдәбияты тарихын өйрәнү тәҗрибәсеннән // Совет әдәбияты. 1955. №11. Б. 99–118.

10. Казанский университет в годы Великой Отечественной войны // Казанский университет. – Электронный ресурс. – URL: [https://kpfu.ru/social/k-75-letiju-pobedy/kazanskij-universitet-v-gody-velikoj-386709.html (дата обращения: 19.07.2024)

11. Постановление ЦК ВКП(б) «О состоянии и мерах улучшения массово-политической и идеологической работы в Татарской партийной организации». 9 августа 1944 г. // КПСС в резолюциях и решениях съездов, конференций и пленумов ЦК. Изд. 9-е, доп. и испр. Т. 7. – М.: Политиздат, 1985. – С.513–520.

12. Измайлов И.Л. Утверждение принудительного булгаризма: постановление ЦК ВКП(б) и его последствия // Реальное время. – Электронный ресурс. – URL: [https://m.realnoevremya.ru/articles/286719-utverzhdenie-prinuditelnogo-bulgarizma (дата обращения: 19.07.2024).

13. Замалетдинов Р.Р., Хабутдинова М.М. История создания отделения татарского языка и литературы в Казанском государственном университете в воспоминаниях преподавателей и первых студентов // Tatarica. 2018. №1(10). С. 91–113.

14. Баһаветдинова Х.З. Галимә Хәкимова Рабига Афзаловна: тормыш юлы һәм эшчәнлеге // Историческая этнология. 2021. Т. 6, №. 1. С. 132–140.

15. Фәйзуллин Р.Г. Илбагар уйлар: фәлсәфи язмалар, әдәби портретлар, хатирә-уйланулар / Равил Фәйзуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 414 б.

16. Тумашева Д.Г. Развитие татарского языкознания в Казанском университете (1944–1995) // Гасырлар авазы. Эхо веков. 1996. №1/2. С. 212–216.

17. Егоров А. Три интервью о А. Гилязове // Казанский альманах. 2009. № 5. С.131−148.

18. Хабутдинова М.М. Венгерский след в жизни и творчестве А.М. Гилязова // Филологические науки в МГИМО. 2018. №1. С.104–112.

19. Бушуева Л.А. Восточный педагогический институт в структуре высшего образования Казани в 1920-е гг. // Из истории и культуры народов Среднего Поволжья. 2023. Т.13, №1. С. 63–-78.

20. Кудашев Г.Х. Хәсән Туфан – студент // Казан утлары. 1987. №2. Б.179–181.

21. Җәләлиева М.Ш. Безнең түгәрәк // Татарстан яшьләре. 1967. 24 сентябрь.

22. Мәхмүдов Ә.Г. Илһам юлдаш булсын сиңа, Илһам! // Татарстан яшьләре. 1984. 1 май. Б. 4.

23. Кәримова Р.С. «Дастан» – студентлар басмасы // Татар-информ. – Электронный ресурс. – URL: https://tatar-inform.tatar/news/dastan-studentlar-basmasy (дата обращения: 19.07.2024).

24. Ширмән Х. Халык «Калеб»не аңладымы? // Сөембикә. – Электронный ресурс. – URL: https://syuyumbike.ru/blog/blogs/khalyk-kalebne-aladymy (дата обращения: 15.08.2024).

25. Белозёрова А. В. Литературные салоны и их роль в процессе развития русской культуры России XIX столетия / А. В. Белозёрова, А. Н. Михайлова // Молодой ученый. 2017. № 22.1 (156.1). С. 3–5.

26. Гыйлаҗев Т.Ш. Тәнкыйди-гыйльми фикердә Тукайның әдәби абруе мәсьәләсе (XX гасырның беренче чиреге) // Габдулла Тукай. – Электронный ресурс. – URL: http://gabdullatukay.ru/tukay-science/scientists/gyjlajev-tahir-tenkyjdi-gyjlmi-fikerde-tukajnyn-edebi-abrue-meselese-xx-gasyrnyn-berenche-chirege/ (дата обращения: 19.07.2024).

27. Закирҗанов Ә.М. Заман белән бергә: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2004. – 175 б.

28. Рәхмәтуллина А., Һадиева Г.К. Балалар сөйләменә фоносемантик анализ (Гөлинә Шәйхи шигыре мисалында) // Хаковские чтения – 2023 [Электронный ресурс]: материалы Международной научно-практической конференции молодых ученых, посвященной памяти заслуженного профессора Казанского университета Вахита Хозятовича Хакова (Казань, 26–27 октября 2023 г.) / под общ. ред. Г.Р. Галиуллиной. – Казань: Издательство Казанского университета, 2023. – 91-94 с. URL: https://kpfu.ru/portal/docs/F1473185455/Sbornik_Khakovskie.chteniya_2023.pdf (дата обращения: 24.07.2024).

# ЛИТЕРАТУРНО-ТВОРЧЕСКИЕ КРУЖКИ КАЗАНСКОГО УНИВЕРСИТЕТА И ИХ РОЛЬ В ПРОЦЕССЕ РАЗВИТИЯ ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЫ XX–XXI ВВ.

**Халиса Хатиповна Кузьмина,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
shirmanx@yandex.ru

**Гульфия Расилевна Гайнуллина,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
gulfiarasilevna@mail.ru

Литературные кружки и творческие объединения являются значимым общественным явлением, демонстрирующим высокий уровень духовной культуры населения. История показывает, что деятельность литературных объединений может не только заложить основу для развития национальной литературы и культуры, но и оказать влияние на государство и его внутреннюю политику, поэтому изучение истории таких объединений актуально и для понимания современного литературного процесса. Казанский университет имеет уникальную историю создания национальных творческих объединений и кружков. Татароязычные литературные кружки в Казанском университете появились в XX веке, несколько раз видоизменились, переформатировались и продолжают свою деятельность и в настоящее время. В данной статье ставится задача описать историю литературных творческих объединений, созданных в Казанском университете, исследовать их деятельность в связи с создавшимися общественно-историческими условиями и средой, выявить преподавателей и писателей, работавших в этой области, и их научно-педагогическую деятельность.

**Ключевые слова:** Казанский университет, литературное творчество, объединение, кружок, писатели, «Аллюки», «Ильхам», «Дастан», «Рухият»

Исследование выполнено в рамках темы ФПСП-2/24.